


*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№5 Январь, 2025 ел*



**Ростәм Миннеханов 2025 елны Ватанны Саклаучы елы дип игълан итте. «Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк», – дип язган бөек галимебез Шиһабетдин Мәржани. Тарихи хәтерне саклау – киләчәк буыннар алдындагы бурычыбыз. Бу безгә буыннар бәйләнешен тирәнтен тоярга, киләчәккә ышаныч белән карарга ярдәм итә», – диде ул. Татарстан Рәисе 2025 елда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы билгеләп үтеләчәген искәртте.**

## “Батырлык ул – рухи матурлык”

Батырлык... Бу сүзгә нинди мәгънә салынган? Аны һәркем үзенең тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, үзенчә аңлый. Кемнәрдер батырлар дигәндә илне дошманнан саклаучыларны гына күз алдына китерә, ә кайберәүләр батыр кешеләрнең көндәлек тормышта булуын да аңлый. Батырлык ул – кешенең эчке дөньясының матурлыгы, аның үзенең тормышына зыян килу куркынычына карамастан кыю гамәлләр башкару сәләте. Батыр кешеләр дип тормышның җитди сорауларын чишәргә сәләтле, рухи яктан көчле затларны атыйлар. Бу сыйфат кешеләрдән тәвәкәллек, чиксез зур ихтыяр көченә ия булуны таләп итә.

Батырлык безгә электән үк билгеле, чөнки илебез тарихы бик күп аяусыз сугышлар, афәтләр кичергән. Тарихыбызда кара эз калдырган Бөек Ватан сугышы еллары һәрбер гаиләгә авырлык китерде, күпме кеше язмышлары белән уйнады. Ул дәһшәтле еллар күпме сабыйны тилмертте, аларның балачакларын урлады, ныгып бетмәгән күпме язмышны утка тотты... Әлеге рәхимсез сугышта безнең илебез солдатларыбызның патриотик рухлы, батыр һәм чыдам булуы нәтиҗәсендә генә җиңеп чыкты.

Бу вакыйгаларга бик күп еллар үтсә дә, алар безнең хәтеребездән бер дә җуелмый. Без кыю солдатларыбызны һәм алар эшләгән батырлыкларны һич кенә дә онытмыйбыз. Шуңа да, һәр елны ямьле язлар җиткәч, Бөек Җиңү бәйрәме көнендә батырларның фотосурәтләре “Үлемсез полк” акциясендә урын ала.

Күп кенә кешеләр фикеренчә, батырлык сыйфатына коткаручылар яки солдатлар гына ия. Әмма ныклап уйлап карасаң, һәр кеше билгеле бер тормыш ситуацияләрендә кыюлыгын күрсәтергә сәләтле. Батырлык сыйфаты күпмедер дәрәҗәдә һәр кешедә дә була. Күп кенә һөнәр ияләренең көндәлек хезмәтләре читтән караганда чын мәгънәсендә батырлык эшләү белән тиң. Мисал итеп, тege яки бу ситуацияләрдә кыюлык күрсәткән полиция хезмәткәрләрен, ут сүндерүчеләрне, тәрбиячеләрне китерә алабыз. Алар эш вазифаларының каһарманлык һәм батырлык булып күренүе турында уйламыйча көн саен үз вазифаларын гадәти эш буларак үти. Шундый очракка тормыштан мисал китерәсем килә. Сүзем безнең милләттәшебез герой-очучы Дамир Йосыпов турында.

2019 елның 15 нче августы Россия авиациясе тарихында мәңгегә уелып калачак, чөнки нәкъ шул көнне очучы Дамир Йосыпов бортында 233 пассажиры булган самолетны кукуруз кырына утырта алды.

Бу көнне Жуков самолеты аэропорттан күтәрелүгә бер төркем акчарлаклар белән бәрелешә. Двигательгә кошлар эләгү сәбәпле ул сафтан чыга. Бортның төзек булмавын аңлап, пилотлар аэропортка кайтырга рөхсәт сорыйлар. Әмма шунда ук икенче двигатель дә эшләүдән туктый һәм шуның аркасында экипажга ашыгыч рәвештә самолетны кукуруз кырына утыртырга туры килә.

Экипаж командиры әлеге ситуациядә югары профессионализмын гына түгел, ә шәхси кыюлыкка, тәвәккәллеккә хәм батырлыкка ия булуын да дәлилли, шуның нәтиҗәсендә бортта булган барлык кешенең гомере дә сакланып кала. Бу вакыйгадан соң самолет командиры Дамир Йосыповка Россия Президенты Владимир Путин карары белән илебезнең иң югары бүләге – Россия Герое исеме бирелә.

Һәр кеше үз гомерендә батырлык эшләргә сәләтле. Көчле ихтыярга ия булганда, барысын да эшләргә була. Әниләрне ярату, туганнарга ярдәм итү, иптәшләреңне хөрмәтләү, бигрәк тә туган илне саклау – батырлык үрнәге ул. Ә безнең илебездә, республикабызда, районыбызда, авылыбызда андыйлар бик күп. Һәм алар безгә үрнәк кешеләр!

**Сөнгатова Гөлнара Зөлкарь кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

## Сызылып таңнар атканда

29 нчы гыйнвар көнне без, 9 нчы сыйныф укучылары “ Сызылып таңнар атканда” спектаклен карадык. Спектакль бик нык тетрәндергеч, күңелгә үтеп керерлек, күзләрне яшьләндерерлек иде. Сугыш чорында барган гап-гади хатын-кызларның тормыш , Ватан өчен көрәшүләрен күреп, хәрби бурычларын үтәгәндә һәлак булуларын аңлагач, күңелләр тетрәнде. Артисларга “Афәрин!”- генә диясе кала.

**9 нчы сыйныф укучылары**






## Дулкынландыргыч бәйрәм

Халкыбызның фашизмны җиңүенә быел 80 ел тула.1945 нче елның дулкынландыргыч 9 нчы мае Ватаныбызның гына түгел, ә бөтен кешелек тарихына кереп калды. Ил чикләренә 1941 нче елның 22 нче июнендә герман илбасарлары басып керә. Зур сынаулар килә илгә , бик зур югалтулар була. Халкыбыз 872 көн блокада да яшәгән. Дошман илебездән куып чыгарылып, тар - мар ителә. Без зур тырышлык һәм зур югалтулар бәрабәренә җиңү алып килгән сугыш һәм хезмәт батырлары белән горурланабыз. Еллар ничек кенә үзгәрмәсен, әлеге шатлыклы һәм шул ук вакытта моңсу бәйрәм илебездә иң мөһим, иң изге даталарның берсе булып калыр.

Бөек Ватан сугышы елларын, анда булган вакыйгаларны без китаплардан укып, кинолардан карап кына беләбез. Күпме ир - егетләр, апалар-абыйлар, яшүсмерләр сугыш кырларында мәңгелеккә ятып калган. Меңәрләгән шәһәрләр җимерелә, авыллар юкка чыга. Әмма тылда калганнар да зур батырлыклар күрсәткәннәр. Хатын-кызлар сугыш вакытында күп авырлыклар кургәннәр. Ләкин ач-ялангач тормыш, авыр хезмәт аларны куркытмаган. Завод-фабрикаларда, басу-кырларда тырышып эшләгәннәр.

Сугыш башланганда минем карт әбием-Мәрьям Шаһимәрдән кызына 32 яшь булган. Ул да Җиңу көнен якынайту өчен барысында эшләгән. Ике берсеннән-берсе кечкенә баласын өйдә калдырып, җәй көне урак урган, кыш көне урманда агач кискән, аннан бушаган арада фронтка җибәрергә җылы оекбашлар,бияләйләр бәйләгән. Аның тормыш иптәше-карт бабам Мәулит Сибгатулла улы да 1941 нче елда сугышка алына. Сугыш кырында күп батырлыклар кыла, ләкин ул әсирлеккә төшә. Бабаем төшенкелеккә бирелмәгән, башка әсирләргә ярдәм иткән, чит телләр белү сәбәпле аларга ризык та табышкан. Ул күп газаплар күргәннән соң, әсирлектән кача алган. Кабат фашистларга каршы сугышуын дәвам итә ул. Бик күп орден -медальләр белән бүләкләнә. Җиңү яулап,туган авылы Балыклыга кайта. Кызганычка каршы, бабаемның ике энесе Галимхан белән Галимҗан абыйлар, әбиемнең абыйсы Әхмәтвәли абый сугыш кырында мәңгелеккә ятып калалар. Сугыштан соң, хуҗалыкны торгызуга, яңа тормыш коруга тотыналар. Иген үстерәләр, балалар тәрбиялиләр.

Мин халкыбызның кылган батырлыкларын һәрвакыт хөрмәт итәм һәм сокланам. Ул елларда әби-бабаларыбыз кылган батырлыкларны онытмыйча, бездән соң килгән буынгада житкерү-безнең бурычыбыз булып тора. Без мәктәптә төрле чараларда катнашабыз. Күргәзмәләр оештырабыз, проектлар яклыйбыз.

Җиңу көне - безнең өчен һәрвакыт горурлык, батырлык символы ул. 9 нчы май Бөек Җиңү көне безнең хәтердә мәңге сакланыр.

**Һадиева Иделия, 5 нче сыйныф укучысы**

| | |
|---|---|
| Тышта бик көчле | Курыкма, песикәй, |
| Кар- буран дулый. | Хәзер , түз бераз |
| Ачып күзләрне | Җылы сөт бирәм, |
| Карап та булмый. | Өйгә алып керәм . |
| Шундый буранда | Сөт ялап туйгач, |
| Бер нәни песи | Нәни пескәем, |
| Туңып үлергә | Рәхмәт әйткәндәй, |
| Житешеп елый. | Сырпаланды яныма килеп. |

**Садриева Ралия 2 сыйныф укучысы**



## Көрәш – милли спорт төре

Көрәш — иң борынгы спорт төрләреннән берсе. Ул бигрәк тә төрки дәүләтләрдә киң таралган. Үзбәкстан, Кыргызстан, Монголия милли көрәше татар көрәшенә охшаш. Ләкин аларда аяк чалырга рөхсәт ителә, ә татар көрәшендә — тыела. Татар көрәшендәгечә кул көчен кулланып, көндәшне әйләндереп аркасына салу исә аларда юк.

Көрәш Россиядә милли спорт төрләре исемлегенә кертелгән.

Кечкенәдән Ильяс көрәш белән шөгыльләнә. Гыйнвар аенда районыбызның Ашыт мәдәният һәм спорт үзәге көрәш залында Әтнә муниципаль районының 2009 елгы һәм аннан да яшьрәк егетләр арасында XIX Спартакиада кысаларында Көрәш ярышы булып узды.

Ярышта барлыгы гомуми белем бирү учреждениеләреннән 8 команда, 56 дан артык яшь көрәшче катнашты. Ярышта 55 кг кадәр авырлыкта 3 урынны сыйныфташыбыз Ахметшин Ильяс алды.

Сыйныфташыбызны җиңүе белән котлыйбыз һәм алга таба да уңышлар теләп калабыз!

**Гатауллина Лилия, 8 сыйныф укучысы**

## Тарихи хәтер

Бүгенгедәй, бар да хәтердә:
Авыл кыры, халык чәчүдә.
Бар да эштә, шат һәм бәхетле...
Бетте шатлык мизгел эчендә.
Килде бу көн! Кайгы-сагыш басты,
Дөнья ямьсезләнде, кояш батты,
Кайчан калкыр кабат җиһанга?
Кайчан тынычланыр бу дөнья?
Китте әтиләр, китте абыйлар,
Барысы да газиз, якыннар.
Дүрт күз белән көтәр аналар,
Тешен кысып түзәр балалар...
Зур газаплар үтте ил халкы,
Бердәм булды, түзде, тырышты.
Килде бу көн! Язгы май иртәсе
Өзелеп көткән ҖИҢҮ китерде.
Инде кебек җиргә тынычлык,
Килде кебек илгә иминлек,
Тик илемнең байлыкларына
Кызыга шул дошман күзләре.
Илне саклый чиктә абыйлар,
Солдат күңелен нигә талыйлар?
Зур сугышлар бер дә тынмыйлар,
Һаман кабынып безне сыныйлар.
Кайчан килер илгә тынычлык?
Кайчан җиңәр солдат дошманны?
Көтә бүген бөтен аналар:
"Кайда калды безнең балалар?"
Ишетик без газиз аналарны,
Сөендерик ятим балаларны.
Тынычлыкны җирдә урнаштырыйк
Һәм тарихи хәтер булдырыйк

**Халикова Фирүзә, 6 нчы сыйныф укучысы**

## Авылым

Бик сагынып кайтам һәрчак



## Кышкы уеннар

Менә салкын кыш житте. Жир өсте ап-ак кар белән капланды.
Мәктәптән кайткач, без урамда уйныйбыз. Тауда чана-чаңгы шуабыз. Малайлар хоккей уйнарга яраталар. Жепшек көннәрдә карны әвәләп кар бабай ясыйбыз. Борынын кишердән, күзләрен күмердән куябыз.
Кышкы матур көннәрдә саф һавада уйнарга бик күңелле. Без кышны яратабыз.

**Брча Амира, 3 нче сыйныф укучысы**



## Бәһа житмәс кыйбат хәзрәт

Без "Әдәби хәзинә» берләшмәсендә, Шиһабетдин Мәржанинең туган көне уңаеннан, «Мәржани» фильмын карадык. Ярты сәгатьлек “Мәржани” фильмында дин галименең туган яклары – безнең районыбыз күренешләре дә мул бирелгән. Әтнә районының Ябынчы, Комыргужа, Арчаның Ташкичү авыллары да бар икән монда. Проектта Әтнә театры артистлары да катнашкан. Шулай ук Казанда, Бохарада, Сәмәрканд шәһәрләрендә дә төшергәннәр фильмны. Татарстан дин әһелләренең, татар галимнәренең олуг галимгә карата фикерләрен тыңладык. Фильмда Мәрҗанинең бала чактан алып олыгайган көненә кадәр тормышын, дини, фәнни эшчәнлеген чагылдырган материаллар тупланган. Татарстан Милли музее, Лобачевский исемендәге фәнни китапханә, архив материаллары кулланылган.
«Әдәби хәзинә» берләшмәсе житәкчесе Алия апа дәрес барышында биргән бу мәгълүматлар белән фильм тагын да баерак, кызыклырак булды. Якташ галимнәребез белән горурлану өчен, аларның тормыш юлын, тарихи әйбәт белергә кирәк шул. Берләшмәдә без шундый эзләнүләр белән шөгыльләнәбез. Ә фильны барыгызга да карарга тәкъдим итәм. Истә кала торган күп мәгълүмат алачаксыз аннан.

**Айсинә Садриева, 6 нчы сыйныф укучысы**




## Матурлык безнең күңелләрдә

Нәрсә ул – матурлык? Матурлыкны һәркем үзенчә күрә. Минемчә, ул иртән таң ату, агачларның язын яфрак яруы, көзен кошларның жылы якка китүләре, кышын дөнья тутырып кар явуы. Матурлык ул әнинең йомшак чәчләре, назлы куллары, йомшак сүзләре.


Әгәр кешенең күңелендә яхшылык, тәүфиклылык сыйфатлары бар икән, ул бар нәрсәне матурлыкка әйләндерә ала.

**Гатауллин Ринат, 3 нче сыйныф укучысы**

Мин туган авылыма.
Безнең кайту зур сөенеч
Әбием һәм бабама.
Туган авылым бик тә матур,
Челтерәп чишмә ага.
Шуңа да күңелем ашкына
Туган ягыма таба.

**Гәрәева Зилия, 4 нче сыйныф укучысы**

## Кроссворд чишәбез




**Вертикаль:**
1. Тәмле, тик алма түгел, Койрыклы, тычкан түгел. , 2. Ай белән килә, көн килгәч китә, 3. Тел өчен ул җавап бирә, 4. Агачка оя кормый, оясы — җирдә, җыры — күктә, 5. Өстәл янында иң кирәге нәрсә? 6. Җәрәхәте юк — авырта, төтене юк — яна.
**Горизонталь:**
7. Жәй дә, кыш та бер төстә, 8. Агач башы тукылдык, тукый-тукый тук булдык, 9. Йомык күз белән дә күреп була, 10. Бит-кулларны корыта,чисталыкны ярата.

## Бул син игелекле...

Кыл яхшылык кешеләргә-
Кеше булыйм дисәң.
Авыр булыр, өсләреңә
Гөнаһ туны кисәң.
Кирәк булса коткарырга
Батып баручыны
Кулың суз да коткар сагыш-
Моңга таручыны
Кеше булып яшим дисәң,
Бул син кешелекле.
Бәхетле көн итим дисәң,
Бул син игелекле.

**“Батырлык көндәлек очрап торган авырлыкларга үҗәтләнеп каршы барганда тәрбияләнә”**

**Н.А.Островский.**